Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Урман-Кәләй авылы башкарма комитеты

КАРАРЫ

21 октябрь 2022 ел №18

Әлмәт муниципаль районы Урман-Кәләй авылы башкарма комитетының 2020 елның 14 маендагы 3 нормерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман-Кәләй авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында»гыкарарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләр турында» 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә

Урман-Кәләй авылы башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Урман-Кәләй авылы башкарма комитетының 2020 елның 14 маендагы 3 нормерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман-Кәләй авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында»гы карарына (Әлмәт муниципаль районы Урман-Кәләй авылы башкарма комитетының 2022 елның 25 июлендәге 11 нормерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

1 бүлекнең 4 пунктында, 2 бүлекнең 5 һәм 8 пунктларында, 3 бүлекнең 10 пунктында һәм 12 пунктның дүртенче абзацында «(яки башка вәкаләтле орган)» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 бүлекнең 15.1., 16.1. пунктларын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Урман-Кәләй авылы, Кәләй тимер юл станциясе бистәсе, Железнодорожная урамы, 38б йорты; Колшәрип тимер юл станциясе бистәсе территориясендә урнашкан махсус стендларда игълан итәргә, шулай ук «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылганнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырым.

Урман-Кәләй авылы башкарма комитеты җитәкчесе Л.Н. Фәләхиев